ISSN 0868-4545



Салават күпере

Журналның бу саны Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев иҗатына багышлана.



Кадерле дускай! Хөрмәтле олкәннәр!

Сүзебезне сораудан башлап китик әле: **Шәвәли** атлы малайны беләсезме соң сез? Белсәгез, белмәсәгез дә, әйдәгез, тагын бер кат танышыйк әле.



Мин — **Шәвәли**,
Шук малай,
Үткен малай,
Ут малай!
Мин — бик уңган,
Өлгер мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!
Бик **тапкыр** мин,
Җыйнак мин,
Мин,
Мин,
Мин бик
Тыйнак мин!

Күрдегезме, белдегезме инде!

Менә кем ул **Шәвәли**!

Әти-әнисе бар микән соң аның? Бар инде, әлбәттә! **Шәвәли**нең әтисе — шагыйрь Шәүкәт Галиев! Әнисе дә Шәүкәт абый була! Кызык бит, ә?

«Салават күпере» бу санында сезне әнә шулар белән таныштыра.

Ә **Шәвәли** атлы малай исә «Сабантуй» газетасында яши. Заманында «Сабантуй» шагыйрьгә **Шәвәли** турында сораулар да биргән иде.

— Шәүкәт абый, **Шәвәли**не ничек эзләп таптыгыз?

Шәүкәт абый:

— Ул минем белән качышлы уйнады бугай. Балалар өчен яза башлагач та. Ә ул Шомбай сыман кыяфәтен, исемен алыштырып шигырьдән шигырьгә күчеп йөргән. Ахырда, холкы-килбәте ачыкланып җиткәч, тиктормас малай шигырь юлларыннан: «Мин — **Шәвәли**!» — дип үзе килеп чыкты.

— Ни өчен **«Шәвәли»**? Альфред, Фердинанд, Радик — тагын әллә ниткән исемнәр булган бит?

— Татарлыгын яшергән сыман, мондый шаукым әле дә бар. Җенем сөйми иде шул кыйбласызлыкны, имеш, урысчасын ничек әйтерләр дип исем сайла! Шуңа күрә, илленче еллар башында үз балаларыма исемне, үҗәтләнеп: Җәмил, Җәмилә, Җәүдәт, Алсу дип куштым. Тагын бер малай бик теләгән идем, **Шәвәли** аның урынына булды...

Шәвәли :


— Малайлар-кызлар! Мин Шәүкәт абыйның шигырьләреннән чыгып киттем бит әле! Менә


— Мин. Әйдәгез, кире кереп китәбез! Шигырьләр дөньясына! Анда кызык! Ай-һай! Андагы маҗаралар! Әйдәгез инде, әйдәгез минем белән! Киттек!

Шагыйрь абый! Мине таныдыңмы! Мин — **Шәвәли**! Әйдәгез, сәяхәткә сезне дә алып барабыз!

© "Салават күпере", 1999 ел

Ай-һай, абый шагыйрь абый!
Дәү үскәнсең!
Мине дә бит
Узып киткәнсең!





THE INTERNATIONAL BOARD ON BOOKS FOR YOUNG PEOPLE AWARDS
A CERTIFICATE OF HONOR
TO

Shaukat Galiev

FOR

Zayats na zaryadke

CHOSEN AS AN OUTSTANDING EXAMPLE OF LITERATURE WITH INTERNATIONAL IMPORTANCE

PRESIDENT INTERNATIONAL BOARD ON BOOKS FOR YOUNG PEOPLE

PRESIDENT HANS CHRISTIAN ANDERSEN AWARD JURY

Күрәсеңме! Шәвәлинең Шәүкәтен нинди бүләк белән хөрмәтләгәннәр! Атаклы балалар язучысы Ганс Христиан Андерсен исемендәге бүләк булыр бу!



Шәвәли: Шәүкәт абый мине дөньяга чыгарды, балаларга танытты.

Ә хәзер шагыйрь Шәүкәт Галиев турында мин сезгә үзем сөйләргә уйлыйм. Мин зур малай инде хәзер.

— Гел-гел, улым, ***Шәвәли****,*
Сорау бирәсең нигә?
— Үсеп җиткәч, синең күк
Җавап бирәсем килә.

Чү! Әллә без дә үсеп җиттек инде? Юк ла, мин һаман **Шәвәли** генә әле. Әмма шуны истән чыгармагыз:

Шәвәли хыялы


Белеп торыгыз,
Моннан соң
Теш сызлау булмаячак —
Безнең тешкә эләкмәгән
Конфетлар сызлаячак!

Кызык бит, әйеме!

Шәвәли:

Балалар! Карагыз әле!

Шәүкәт абый кайчандыр үзе дә безнең кебек бәләкәй булган икән ич! Менә бу шигырьне дә алайса үзе хакында язгандыр әле, үзенең хыялын.



Шәүкәт Галиев. 1998 ел.

Көлке бүлмәсе

Түп-түгәрәк бер бүлмәгә
Күп көзгеләр тезгәннәр.
Шунда кереп, үзен күреп
Юктыр көлми түзгәннәр!

Менә килә усал апа,
Йөз чытып, каш җыерып.
Килеп кергәч ул да көлә —
Торалмый һич тыелып.

Милиционер абыйлар да
Бу бүлмәгә керәләр.
Бер тамчы ачуланмыйлар,
Пырх-пырх көләләр.

Эх, безнең өйдә дә шундый
Кызык бүлмә булсачы,
Елаган чакта сеңелем
Шунда кереп торсачы.

«Икеле» алганны әткәй
Шул бүлмәдә белсәче,
Тырышса да, орышалмый
Шырык-шырык көлсәче!

Елмаясың, көләсең син.
Ник шигырь укымыйсың?
Белдем инде, аңладым мин.
Син үзең укы дисең!





Күрдегезме! Бәләкәй вакытта Шәүкәт абый үзе дә безнең кебек хәйләкәр булган икән, ә! «Икеле»дән ничек ансат кына котылмакчы!

Шәүкәт Галиев «бишле»гә укучылар арасында.



Олы Кайбыч урта мәктәбенең IV сыйныф укучылары.
Сул почмакта, иң өстә – Шәүкәт Һидиятуллин.
1940 ел, 20 май. Кайбыч.



Шәүкәт Галиев Казандагы 10 нчы гимназия укучылары арасында.
1997 ел, 29 октябрь.



Әйдәгез, укыйбыз!



Чебешләр оча

Оча, оча, чебешләр оча!
Чебешләр оча саллар өстеннән,
Чебешләр оча таллар өстеннән,
Чебешләр оча таулар өстеннән!

Оча, оча, чебешләр оча!
Чебешләр оча балалар өстеннән,
Чебешләр оча калалар өстеннән,
Чебешләр оча далалар өстеннән!

Оча, оча, чебешләр оча!
Чебешләр оча клублар өстеннән,
Чебешләр оча болытлар өстеннән,
Чебешләр оча котыплар өстеннән!

Оча, оча, чебешләр оча!
Тилгәннәр дә куып җиталмыйлар,
Ябалаклар алып киталмыйлар,
Каргалар да азык италмыйлар!

Оча, оча, чебешләр оча!
Чебешләрнең эш хутта —
Чебешләр оча самолетта!

Горурлыгына
аның кагылма,
Котбетдин хәтәр
ачуы чагында!
...Котбетдин мәргән
сезгә ук биргән!

Шәүкәт абыйның «Котбетдин мәргән» дигән шигъри әсәрен беләсезме сез? Беләсез, әлбәттә. Менә шулай башланып китә ул:

Иртән үк торып,
Тамакны кырып,
Мыекны борып,
Мылтыкны корып
Котбетдин мәргән
Ауга киткән ди...



Сынчы Әхсән Фәтхетдин Котбетдин абзыйның сурәтен дә эшләгән. Агачтан юнып.

Ә болары, болары инде... Шәүкәт абыйның бертуган «Шәвәлиләре».



Шәүкәт Галиев хатыны Фәридә, кызлары Җәмилә, Алсу һәм улы Җәүдәт белән. 1967 ел.





Шәүкәт Галиев олы улы Җәмил белән. Кайбыч. 1953 ел, июль.



«Чаян» редакциясендә Яңа елны каршылау. Шәүкәт Галиев улы Җәмил, кызы Җәмилә белән. 1958 ел, 5 гыйнвар.



Шәукәт абый сәхнәдән шигырь укый. Беләсезме аның нинди шигырь укыганын? Ә мин, Шәвәли, беләм. Менә ул:



Шәукәт Галиев. Апас. 1987 ел, 25 март.

Менә нинди чебиләр

Ай чебиләр, чебиләр,
Минем белән йөриләр.
Йөгерсәм — йөгерәләр,
Сикерсәм — сикерәләр,
Су керсәм — су керәләр —
Менә нинди чебиләр!

Ай чебиләр, чебиләр,
Тәмам җанга тиделәр.
Йөртәсең саклап кына:
Ашыйлар сайлап кына,—
Я май, я каймак кына —
Менә нинди чебиләр!

Ай чебиләр, чебиләр,
Бер дә чип-чип димиләр;
Үзләре тик яталар,
Мине чыелдаталар.
Менә нинди чебиләр,

Шәвәли: Әйдәгез, шагыйрь абыйларның үзләренә дә багышлап бер шигырь чыгарыйк әле.



Наян белән Шаян

Бер дә бер көнне
Наян белән Шаян
Дәшкән кунакка
Шагыйрь абыйны,
Ике абыйны.

Белгәннәр каян,
Сизгәннәр каян,
Алар киләсен,
Бик, бик яратып
Шигырь сөйләсен.



Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеев янына телевидениедән Наян белән Шаян кунакка килгән. 1997 ел, 29 сентябрь.

Шәвәли:
Шәүкәт абый
кайда йөри икән?
Шәвәлия апа һәм
Шәвәлиләр
Аны көтә,
сагынып көтә.



Шәүкәт Галиевнең хатыны Фәридә, балалары Җәмил, Җәүдәт, Алсу, Җәмилә.



Шәүкәт Галиевнең балалары Җәмилә, Алсу, Җәүдәт һәм аларның дуслары. 1961 ел.

Әйе, күп йөри шул Шагыйрь абый. Менә әнисе Хәлимә апа да аны сагынып көтеп алган



Шәүкәт Галиев әнисе Хәлимә, хатыны Фәридә, улы Җәүдәт белән. 1964 ел, апрель.

Бүген безгә бик күңелле,
Бу бит бергә булган көн.
Һаман шулай бердәм итсен
Очраштырсын туган тел!

Рәхмәтләр хакында

Җиргә төшкәч
Бияләе
Гафур алып
Биргән иде,
Динә аңа:
— Рәхмәт,— диде.

Малайның да
Җылы сүзгә
Кәеф килде.
Елмайды да:
— Рәхмәтеңә
Рәхмәт! — диде.

Кыз җавапсыз
Калсын диме?
Җавап бирде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәт инде!

Малай аңа
Башын иде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәтеңә
Рәхмәт,— диде.

Динә көлде.
Бик күңелле,
Рәхәт иде.
...Җиргә төшкән
Бияләйгә
Рәхмәт инде!..



Без - Тукай оныклары

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без - Туган телдән туганнар,
Без - Тукай оныклары!



Казандагы 55 нче мәктәпнең А.Алиш музеенда укучылар белән очрашу.
1982 ел, декабрь.







Гөмбә җыйганда. Шәүкәт Галиев балалары Җәмил, Җәмилә, Җәүдәт һәм Алсу белән. 1964 ел, сентябрь.



Кайтып киләм урманнан

Буш кәрзинне элеп мин
Кайтып киләм урманнан,
Карап кала кешеләр:
«Моның юлы уңмаган...

Фәлән-фәлән малайлар,
Әнә, исең китәрлек —
Җиләк-гөмбә җыйганнар
Кыш буена җитәрлек!»

Сыямыни кәрзингә
Имән-Алып батырлар?
Кәккүкләрнең моңнарын
Ничек салып кайтырга?

Яшел чирәм юлларны,
Ак чәчәкле аланны,
Һәр ошаган нәрсәне
Мин соң ала аламмы?!

Җирдән чыккан нур булып,
Ак каеннар басканнар,
Яктыртыйк дип дөньяны,
Кояшка тоташканнар!

Бүген күргәннәремне
Санасаң, искитәрлек,
Күңел тулы матурлык —
Гомерлеккә җитәрлек!



Татарстан китап нәшриятының музеенда Муса Җәлил гаиләсе белән очрашу. Әминә Җәлил, кызы Чулпан, оныгы Таня. Уңнан Г.Шәрәфетдинов, Н.Габитов, Әминә Гыйззәтуллина, Сәлимә Мөстәкыймова, Ш.Галиев. 1981 ел, февраль.

Муса Җәлилнең кызы Чулпанга килеп җитмәгән хаты.

«...җиңгәч, мин өйгә кайтырмын. Синең туган көнеңне бәйрәм итәрбез. Мин сиңа бик яхшы бүләк бирергә җыенган идем, кайткач бирермен».

М.Җәлилнең фронтка барганда кызы Чулпанга язган хатыннан. 28 февраль, 1942 ел.

Көткәнсеңдер нәни чагыңда,
Үскәч инде үзең аңладың,
Вакытында кайта алмадым,
Тик барыбер читтә калмадым –
Азат илем сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа бәхет теләдем –
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Сагынуларым калды мәңгегә –
Җырга барсын сала алмадым...
Белеп киттем, якты дөньяда
Мәхәббәтем исән калганын –
Газиз әнкәң сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа шатлык теләдем –
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Кичер, балам, кичер әткәңне,
Мин сүземдә тора алмадым,
Туган көндә була алмадым...
Тик бурычлы булып калмадым –
Җиңү булды сиңа бүләгем,
Мин тыныч көн сиңа теләдем –
Кадерен бел, балам, кадерен!

Шәвәли:
— Кем сезне таныштырды,
Ни сезне якынайтты?



Мирсәй Әмир, Шәүкәт Галиев. 1971 ел.

Шәвәли сүзе:

Борын-борын замандамы,
Кайбычтамы, Казандамы?
Юк ла! Әле кичә,
Кайчан гына
Аксакаллар янында
«Яшь сакал» идең әле!
Ә бүген
«Аксакал» бит син үзең!

Танышмак өчен табышмак

«Үти-үти!» дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«Кыйгак-кыйгак»,— дип килерме,
Кем җавап бирер?

«Ти-ти-ти-ти!» — дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«Бак-бак, бак-бак»,— дип килерме,
Кем тавыш бирер?

«Мәh-мәh, мәh-мәh!» — дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«Мияу-мияу»,— дип килерме,
Кем тавыш бирер?

«Пес-пес, пес-пес!» — дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«hау-hау, hау-hау!» — дип килерме,
Кем җавап бирер?

Кайчан да кайчан барсы да
Дөп-дөрес килер,
Әнием шул чак аларга
Ашарга бирер:

Үрдәккә — ботка салыр,
Тавыкка тары сибәр,
Казга бәрәңге изәр,
Мәчәйгә — шулпа куяр,
Ә **песигә** — сөт кояр!









Абдулла Әхмәт (уңда) **һәм Шәүкәт Галиев**. Аккош күле. 1965 ел, август.



Гомәр Бәширов, Шәүкәт Галиев. Аккош күлендә. 1964 ел, сентябрь.





Хәсән Туфан белән Шәүкәт Галиев Иделдә. 1963 ел.

Атлап чыктым Иделне

Сыгандым да балакны,
Таяндым да таякны,
Суздым гына аякны —
Атлап чыктым... Иделне.

«Булмас, булмас!» — дисеңме?
Кем ялган сөйли, минме?
Чын-чынлап чыктым инде:
Нәни иде Иделе —
Башланган җире иде!



Кыя һәм Кеше

Ш.Галиевнең
Х.Туфанга багышланган
балладасыннан өзек.

...Ул көннәрдән соң
Күп еллар үткән.
Дауларда Кеше
Күп юллар үткән.

Кырык давылда
Айкалган Кеше,
Кырык батып та
Сау калган Кеше.

Чәче — ак дулкын,
Үзе гел чандыр...
Бу якларда ул
Булган кайчандыр.

Бүген дә алар
Тагын икесе:
Торалар бергә —
Кыя һәм Кеше.

Күптәнге бәхәс
Инде чишелгән —
Кыя яртылаш
Иңгән, ишелгән...

Сизә карышып
Файда юклыгын:
— Эх, булса миндә
Кеше ныклыгы!..

Сораган Кыя:
— Әйт, Кеше, сөйлә,
Мондый көч сиңа
Кайлардан килә?

Һәм Кеше әйткән:
— Кыя, Кыя-таш,
Йөрәгем минем
Халыкка тоташ!





Шәүкәт Галиев укучылар белән очрашуда. 1981 ел.

Шул ук бер күңел икән...

Роберт Миңнуллин

Егерме яшь юктыр арада.
Шәүкәт Галиев.

Егерме яшь шул арада.
Уйласаң, күп бит инде.
Аерма, мин сиңа әйтим,
Җир белән күк бит инде.

Шулай да без фикердәшләр,
Каләмдәшләр, эштәшләр.
Очрашканда, әйтерсең лә,
Икебез дә яшьтәшләр.


Кайчагында булабыздыр
Шаян малай-шалай да.
Җитдилекне, шигърилекне
Югалтмыйбыз алай да.

Очрашсак, мин олыгаям,
Син китәсең яшәреп.
Моңа чаклы икебез дә
Менә шулай яшәдек.

Минем өчен син гомерлек
Остазым да, тиңем дә.
Арага җил дә кермәде,
Дошманны әйтмимен дә.

Гел яклаштың усаллыктан, —
Дәш кенә, эндәш кенә!
Мин үземме? Белмим инде,
Мин бит энекәш кенә.

Яшьлектә дә, картлыкта да
Шул ук бер күңел икән...
Арадагы егерме яшь
Бик күп тә түгел икән.



Шәүкәт Галиев Роберт Миңнуллин белән Казандагы 55 нче мәктәпнең А.Алиш музеенда. 1982, 27 декабрь.



Шәвәли:

Бик әүвәлге заманда,
Бакырчыда, Казанда
Яшәгән ди бер абый,
Һәм яши ди бер абый,
Үзе абый, үзе сабый,
Дөньяга ул
Шигырь аша карый.

Һәр баланы җайлый,
Һәркем аны таный,
Шигъри теле һаман
Былбыл булып сайрый.
Ул — **Шәвәли Гали**,
Ул — **Шәүкәт Гали.**





Туган тел – иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма –
Туган телне онытма!

Ш Гали

Салават күпере

10(116) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪ
ЛУМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫ
ГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГ
ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле
чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информаци и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмә һәм матбугат министрлыгы тара фыннан 96 нчы номер белә теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 17.9.99 ел.
Басарга кул куелды 17.9.99 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 12593 данә. Заказ 3-543.
Бәясе килешү буенча.

POINT

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

НИНДИ БУЛА ЯҢА ЕЛ



Шап итте дә нәрсәдер
Төште куян каршына.
Күтәрелеп караса
Биек чыршы башына —
Анда утыра тиен,
Селкеп тора тәпиен.
Чикләвекне куянга
Юри ташлап куйган ла,
Юри туктаткан дусын:
— Яңа ел котлы булсын!
— Яңа ел котлы булсын!
Тиен котлый куянны,
Куян котлый тиенне.
Сикерештеләр инде,
Сөенештеләр инде!
Тәмле-тәмле бүләкләр
Чыршыларның төбендә,
Әйлән-бәйлән уйныйлар
Анда, монда, тегендә!
...Тиен әйтте яз җиткәч,
Очратты да куянны:
— Кызык иде Яңа ел!
Шул чак аю уянды,
Тирә-якка каранды,
Үзе усал, үзе ач.
Кыш буена йоклагач
Аңлашылмый аңа ул:
— Нинди була Яңа ел?
Тәмлеме ул Яңа ел?
— Тәмлесен бик тәмле дә,
Бик тиз үтеп китә шул:
Йоклаган — белми кала,
Белмәгән — йөрми кала,
Йөрмәгән — күрми кала,
Күрмәгән — көлми кала!

